# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**12.11.2021 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 12 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2022 елда, Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

-Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары (тракторчы белән техниканы арендалау, килешү буенча хезмәт өчен түләү, сыешлыкны арендалау);

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Үчәлле авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар: агачлар, чәчәкләр, куаклар сатып алу һәм утырту; территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырып чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм тример өчен запас частьләр сатып алу, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре, балалар өчен уен, спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, территорияне санитар чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү: санкцияләнмәгән чүплекне рекультивацияләү);

РИЗА КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 206 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенда катнашып тавыш биргән гражданнар саны - 160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 156, «КАРШЫ» позициясе өчен 4 граждaннар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре- гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2022 елда, Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

-Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары (тракторчы белән техниканы арендалау, килешү буенча хезмәт өчен түләү, сыешлыкны арендалау);

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Үчәлле авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар: агачлар, чәчәкләр, куаклар сатып алу һәм утырту; территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырып чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм тример өчен запас частьләр сатып алу, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре, балалар өчен уен, спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, территорияне санитар чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү: санкцияләнмәгән чүплекне рекультивацияләү).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Граждaннар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина